ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

15.12.2025 г. Казань № 544-120/тэ-2025

Зеленодольск муниципаль районы «ПЭСТ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан җылылык энергиясен тапшыру хезмәте күрсәтүгә 2026-2030 елларга тарифлар билгеләү хакында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя билгеләү турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 15.12.2025 ел, № 32-ПР утырыш беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Зеленодольск муниципаль районы «ПЭСТ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (алга таба – «ПЭСТ» ҖЧҖ) тарафыннан күрсәтелүче җылылык энергиясе тапшыру хезмәтләренә, шушы карарның 1 нче кушымтасына туры китереп, календарь буенча бүленгән тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2026 елның 1 гыйнварыннан 2030 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Әлеге карарның 2 нче кушымтасы нигезендә 2026-2030 елларга билгеләнгән тарифларны индексацияләү ысулын кулланып тарифлар формалаштыру өчен җайга салуның озак сроклы чорына билгеләнә торган җайга салуның озак сроклы параметрларын билгеләргә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис Р.В. Гайнетдинов

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
15.12.2025 № 544-120/тэ-2025
карарына 1 нче кушымта

## «ПЭСТ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан җылылык энергиясен тапшыру буенча күрсәтелә торган хезмәтләргә 2026-2030 елларга календарь буенча бүленгән тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлек, җайга салынулы оешма атамасы | Тариф төре | Ел | Җылылык китерү матдәсе төре | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Су | Пар |
| | Зеленодольск муниципаль районы | | | | |
| | «ПЭСТ» ҖЧҖ | Кулланучылар өчен, тоташтыру схемасы буенча тарифлар дифференциацияләнмәгән очракта | | | |
| | | бер ставкалы, сум/Гкал | 01.01.2026 башлап 30.09.2026 кадәр | 680,00 | - |
| | | | 01.10.2026 башлап 31.12.2026 кадәр | 763,36 | - |
| | | | 01.01.2027 башлап 30.06.2027 кадәр | 713,36 | - |
| | | | 01.07.2027 башлап 31.12.2027 кадәр | 688,24 | - |
| | | | 01.01.2028 башлап 30.06.2028 кадәр | 588,24 | - |
| | | | 01.07.2028 башлап 31.12.2028 кадәр | 702,13 | - |
| | | | 01.01.2029 башлап 30.06.2029 кадәр | 622,13 | - |
| | | | 01.07.2029 башлап 31.12.2029 кадәр | 578,32 | - |
| | | | 01.01.2030 башлап 30.06.2030 | 548,32 | - |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | кадәр | | |
| | | | 01.07.2030 башлап 31.12.2030 кадәр | 784,86 | - |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф карарларын кабул
итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү
бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының
15.12.2025 № 544-120/тэ-2025
карарына 2 нче кушымта

Билгеләнгән тарифларны индексацияләү ысулыннан файдаланып тарифлар формалаштыру өчен 2026-2030 елларга җайга салуның озак сроклы чорына билгеләнә торган озак сроклы җайга салу параметрлары

| т/с | Муниципаль берәмлек, җайга салынулы оешма атамасы | Ел | Операция чыгымнарының база дәрәҗәсе | Операция чыгымнарының нәтиҗәлелек индексы | Энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | Җылылык челтәренең матди характеристикасына технологик югалтулар күләменең мөнәсәбәте | Технологик югалтулар |
| | | | мең сум | % | Гкал/$м^2$ | Гкал |
| Зеленодольск муниципаль районы | | | | | | |
| 1 | «ПЭСТ» ҖЧҖ | 2026 | 11 307,00 | 1 | 0 | 5 969,28 |
| | | 2027 | Х | 1 | 0 | 5 969,28 |
| | | 2028 | Х | 1 | 0 | 5 969,28 |
| | | 2029 | Х | 1 | 0 | 5 969,28 |
| | | 2030 | Х | 1 | 0 | 5 969,28 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге